МИНИСТЕРСТВО
ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

24.04.2024 № 27

Казан ш.

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүне законнарга туры китерү максатыннан боерык бирәм:

1. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Билгеләргә:

бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә;

әлеге боерык белән расланган үзгәрешләрнең 2 пунктының дүртенче абзацы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге боерык белән расланган үзгәрешләрнең 2 нче пунктының өченче, бишенче, алтынчы абзацларын 2024 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә җәелдерергә.

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының
24.04.2024 № 27
боерыгы белән расланды

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 10 мартындагы 57 номерлы боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү (шул исәптән капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү һәм мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын арттыруга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә булган рөхсәткә үзгәрешләр кертү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында 2.6.8 пунктның 6 пунктчасын киләсе редакциядә бирергә:

«6) капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүне аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә башкару планлаштырылган очракта, ә территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру килешү төземичә башкарыла икән, – территорияне комплекслы үстерү турында карар күчермәсе (шул ук вакытта Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп, комплекслы үстерелергә тиешле территория чикләрендә капиталь төзелеш объектларын төзегән, реконструкцияләгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында мондый килешүләрнең һәм (яки) карарның күчермәләрен тапшыру таләп ителми) – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгыннан».

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 25 маендагы 126 номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктта:

4 нче пунктта «экологик күзәтчелек» сүзләрен «экологик контроль (күзәтчелек)» сүзләре белән алмаштырырга;

5 пунктчада «, аңа карата «Күчемсез милек объектларының аерым төрләренә хокукларны рәсмиләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон нигезендә дәүләт кадастр исәп-хисабы һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәве гамәлгә ашырылмый торган

капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшырган очракта;»;

2.6.6 пунктының дүртенче абзацында «экологик күзәтчелек» сүзләрен «экологик контроль (күзәтчелек)» сүзләре белән алмаштырырга;

3.6.1 пунктының өченче абзацында «экологик күзәтчелек» сүзләрен «экологик контроль (күзәтчелек)» сүзләре белән алмаштырырга.